Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз алтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 ноябрь, 2023 ел № 278

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 27 октябрендәге 107 номерлы карары (Питрәч муниципаль районы Советының 2022 елның 28 февралендәге 141 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегенең 1.2 өлеше:

- беренче абзацта «энергетика нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы законнар» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яисә) квартал эчендәге газ җиһазларын имин эксплуатацияләүгә һәм аларга техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күпфатирлы йортта вентиляция һәм төтен каналларын тотуга карата таләпләр.».

1.2. 1.6 өлешенең 1, 2, 3 пунктларында «1-11» санын «1-12» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов